# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Матвеевка торак пунктында
2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

№ 6 27.11.2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Иске Матвеевка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Матвеевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,түбәндәгеләрдән тыш:көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I һәм 2 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар,Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр,мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-Иске Матвеевка торак пунктында Луговая урамындагы торак юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китертү, салу, килешү буенча эш өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Халык җыенында рәислек итүче: __________ М.Н. Галимҗанов
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Иске Матвеевка авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе М.Н.Галимҗанов
(имза) (имзаның аңлатмасы)